РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Сарлинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы,
423315
Тел. 365-34

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты

423315, Сарлы авылы,
Үзәк урам, 68А,
Тел. 365-34

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
КАРАР

«06» февраль 2019 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 елдагы 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында карар бирәм:

1.Расларга:

1.1. Белешмә (Өземтә) бирүнең административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2. Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча административ регламент (2 нче кушымта);

1.3. Агач һәм куаклар кисүгә рөхсәт бирү административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4. Муниципаль милектәге гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү буенча административ регламент (4 нчы кушымта);

1.5. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алыштыру буенча документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты (5нчы кушымта);

1.6. Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итүнең административ регламенты (6 нче кушымта);

1.7. Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль милекне арендага бирү буенча административ регламент (7 нче кушымта);

1.8. Аукцион уздырмыйча стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга килешү төзүнең Административ регламенты (8 нче кушымта);

1.9. Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне автомобиль йөртүгә рөхсәт бирү административ регламенты (9 нче кушымта);

1.10. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирүнең административ регламенты (10 нче кушымта).

1.11. Документлар күчермәләренә һәм алардан өземтәләргә тугрылык таныклавының Административ регламенты (11 нче кушымта);

1.12. Васыятьнамәләр һәм ышанычнамә таныклыклары административ регламенты (12 нче кушымта);

1.13. Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт торак урыны наймы шартнамәләре буенча торак урыннары бирүнең административ регламенты (13 нче кушымта);

1.14. Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты (14 нчы кушымта);

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 2016 елның 12 маендагы 7 номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында.

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов